Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№2 (29)

Декабрь, 2018 нче ел

## Мәктәп директорларыбыз



**Демидов Рафаэль Тимофей улы**

**2003**



**Насырова Нәкыя Мирзанур кызы**

**2006**



**Мирзаянов Азат Фәрит улы**

**2014**

## ЮБИЛЕЕҢ БЕЛӘН, ГИМНАЗИЯ!







***Зур тарихның башы кечкенә вакыйгадан башлана. 2003 нче елда №3 урта мәктәп буларак ачылган һәм бүгенге көндә “Мөслим гимназиясе” статусына ия булган уку йорты үзенең 15 еллык юбилеен билгеләп үтә.*** Менә 15 ел инде без беренче сыйныф укучыларын үз стеналарыбызда кабул итеп, алардан белемле, тормышка яраклашкан шәхесләр тәрбияләп чыгарабыз. Татарстан Республикасы электрон белем бирү системасында компетенция үзәге буларак, гимназия укытуда инновацион технологияләрне кулланышка кертүдә алдынгы тәҗрибә тарату базасы булып тора. Яңалыкка омтылучан педагоглар, укучы эшчәнлеген оештыруның отышлы формаларын кулланып, укыту-тәрбия юнәлешендә күркәм нәтиҗәләргә ирешәләр. Гимназия “Гомуми белем бирү программасының планлаштырылган нәтиҗәләренә ирешү шарты буларак уку һәм дәрестән тыш эшчәнлекне интеграцияләү” темасы астында эшли.

Сәләтле укытучы гына балаларның сәләтен үстерә ала дигән гыйбарә яши. Гимназия – профессионаллар территориясе. Педагоглар һөнәри осталык бәйгеләрендә бик теләп катнашалар, профессиональ осталыкларын үстерәләр, республика, регионара чараларда үз тәҗрибәләрен тараталар. Гимназия укытучылары арасында “Ел укытучысы”, “Сыйныф житәкчесе” республика бәйгесе, “Мастер-класс” Бөтенроссия конкурсы, “Авыл укытучысы” республика конкурсы җиңүчеләре, төрле Грант иясләре бар.

Гимназия – бердәм эшләүче тупланган коллектив. Башлангычтан алып, югары сыйныфларга кадәр эзлеклелек, дәвамчанлык саклана. Һәр ел саен йөздән артык укучының муниципаль олимпиадаларда җиңүче һәм призер булуы, республика олимпиадаларында, Бөтенроссия, Халыкара олимпиадаларында нәтиҗәләребез булу һәм ОГЭ, ЕГЭ күрсәткечләренең югары булуы – бердәм хезмәт нәтиҗәсе.

Гимназия өч ел рәттән “Тулы көн мәктәбе” муниципаль проектын тормышка ашыру юнәлешендә эшли. Укучылар күп төрле түгәрәкләргә, спорт секцияләренә тартылган. Хореография, шахмат, “Арт-дизайн”, “Робототехника” түгәрәкләре, “Маска”, “Балкыш” сәхнә осталыгы түгәрәкләре, “Музыка дөньясында” сәнгать студиясе, ике телдә “ТЫЛСЫМ+”, “КЛЮЧ” газеталары проектлары дәвамлы проектлар буларак тормышка ашырыла. Укучыларыбыз “Йолдызлык” республика, “Яшь бөреләр” район фестивале, “Илһам”, “Ак җилкән” яшь язучылар бәйгеләре җиңүчеләре, “Көмеш кыңгырау” балалар гәҗитенең даими хәбәрчеләре.

Спорт буенча уңышларыбыз шактый. Ике ел рәттән гимназия укучылары командасы Анапа шәһәрендә узган “Президент ярышлары”нда катнашып, яхшы нәтиҗәләргә иреште. Гимназия укучылары милли көрәш һәм билбау көрәше буенча республика, Россия командасы составында ярышларда катнашты. Укучылар спортның барлык төрләре буенча яхшы күрсәткечләргә ирешеп киләләр.

***620 укучы 11 нче сыйныфны тәмамлап, 85е медальгә ия булды.***
***778 укучы 9 нчы сыйныфны тәмамлап, 59ы аерым урнәктәге аттестат алды.***

Гимназия елъязмасында үз эзен калдырган шәхесләр - укытучыларыбыз һәм укучылар өчен бу зур бәйрәм.

Бердәм булганда, бернинди авырлыклар да киртә була алмый. Бердәмлектә – көч.

Юбилееӊ белән, гимназия!

***Мирзаянов А.Ф.,***
***гимназия директоры***

# ГИМНАЗИЯ – СЫЙФАТЛЫ БЕЛЕМ ГАРАНТЫ

## ФӘН БӘЙГЕЛӘРЕ КӨНДӘЛЕГЕ



Ноябрь-декабрь – барлык фәннәр буенча Бөтенроссия һәм республика олимпиадаларының муниципаль этабы уза торган катлаулы чор. Кайбер фәннәр буенча инде нәтиҗәләр билгеле. Гимназия укучылары арасында белеме белән башкалардан өстенлекләрен исбат итүче иң тырыш укучылар белән сез танышмы?

Фәхертдинова Айгөл (биология, экология, тарих), Зиязова Миләүшә (биология, экология, инглиз теле), Баянов Шамил (математика, биология, инглиз теле, география), Шәрифуллина Алсу (математика, биология, инглиз теле), Хәбибуллина Лиана (инглиз теле, сәнгать), Зиязова Диләрә (рус теле, биология),

***«Очраклы ачышларны бары тик әзерлекле акыллыбашлар гына ясый». Бу турыда француз математигы, механик, физик Блез Паскаль 17 гасырда ук әйтеп калдырган. Моннан 400 елдан элек әйтелсә дә, 21 гасырда да актуаль яңгырый бу сүзләр.***

Ханнанова Алина (биология, экология), Фәхртдинова Айсылу (биология, экология) фәннәреннән җиңүгә ирештеләр. Бүгенге көнгә муниципаль этапта 54 призлы урын яуланды.

*Уңышларыгыз дәвамлы булсын! Яңа үрләргә!*

# ГИМНАЗИЯ – ТӘРБИЯ УЧАГЫ

## УКУЧЫЛАР ҮЗИДАРӘСЕ – ЛИДЕРЛАР МӘКТӘБЕ

Яңа уку елы башында сайлап куелган укучылар үзидарәсенең яңа составы "Лидерлык мәктәбе" проекты буенча эшли башлады. Районда җитәкчелек вазифаларын башкаручылар белән "Иртәнге чәй" кысаларында әңгәмәләр оештырыла. Бездә кунакта район иҗтимагый советы җитәкчесе М.Ш.Йосыпов, район администрациясе вәкилләре Р.Г.Гарипов, М.Р.Бәдретдинова һ.б. булдылар. Лидерлык буенча киңәшләр бирделәр, үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Алар белән әңгәмәләрдән, без үзебез өчен "Алтын кагыйдәләр җыентыгы" тупладык. Кайбер фразаларны сезгә тәкъдим итәбез:

•Үз туган җиреңне чын бирелгәнлек белән ярат!

•Үз уку йортыңның горурлыгы бул, абруен арттыру өстендә үзеңне аямыйча эшлә!

•Гади бул!

•Үзеңә нинди яхшылык телисәң, башкаларга да шуны телә!

•Зур планнар кор, әмма вак-төяк шатлыкларга да сөенеп яши бел!

•Иң зур җиңү – үз-үзеңне җиңү! *(Полководец Суворов сүзләре)*

•Сөйләшкәндә әңгәмәдәшеңнең күзенә карап сөйләш.

•Башкаларны гаепләмә, үз гаебеңне танырга өйрән!

•Үзеңнең белмәвеңнән оялма: белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү – гаеп!

•Әйткән сүзеңдә тор, вәгъдә иткән эшеңне төгәл үтә! Буш сүз сөйләмә!











•Үз-үзеңә таләпчән бул!

•Эшеңне планлаштырырга, вакытыңны дөрес бүләргә өйрән!

•Уртак эштән читтә калма! Авырлыкларны бергә җиңәргә өйрәнегез.

•Инциативалы бул! Башкаларга үрнәк күрсәт!

•Үзеңне дә, башкаларны да кичерергә өйрән.

•Һәрчак үз белемеңне, осталыгыңны арттыру юнәлешендә эшлә. Камиллеккә чикләр юк.

•"Рәхмәт" сүзен ешрак әйт!

•Үзеңә теләктәш кешеләрне аера бел!

Алга таба да мондый гамьле әңгәмәләр дәвам итәчәк. Киләчәк тормышыбызда бу киңәшләр барыбызга да файдалы булыр дип ышанабыз.

***Эльгина Мирзаянова, укучылар үзидарәсе әгъзасы***

## УКЫ, ӨЙРӘН, ҮСЕШТӘ БУЛ!

# СЕЗДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ – ШУЛАЙ ДӘРЕСЛӘР РӘХӘТ ҮТӘ

***Гимназия укучылары кайсы дәресләрне үз итә?*** Шундый сорау белән, үзебезнең укучыларга мөрәҗәгать иттек.



**Алина Ханнанова:**

Хәзерге дәресләр укучыларның үзара хезмәттәшлегенә нигезләнеп оештырыла. Парларда, төркемнәрдә эш алымнары кулланыла. Минемчә, уку хезмәтен болай оештыру коммуникатив мөмкинлекләрне үстерергә ярдәм итә. Без үзара аралашырга, бер-беребезнең фикерен тыңларга, килешмәгән очракта, тактлы итеп кире кагарга, үз фикеребезне әйтергә өйрәнәбез. Бүгенге заманда, әлбәттә, кеше белән аралашу культурасына ия булу – бик әһәмиятле сыйфат.

**Булат Микалин:**

Мина дәрес темасын үзебез табу процессы ошый. Укытучылар тәкъдим иткән биремнәрне үтәү барышында без ачыкларга тиешле мәсьәлә калкып чыга. Шуны тоемлап алсаң – син дәрес темасын формалаштыра аласың дигән сүз. “Балалар, бүген без фәлән тема үтәбез...” дип башланган дәресләр юк бездә. Дәрес – үзе бер проект. Дәреснең уңышлы булуы укытучыларыбызның осталыгыннан тора. Зөлфирә Мухаровна, Венера Гайсовна дәресләре миңа аеруча ошый. Без тәҗрибәләр эшлибез, проектлар ясыйбыз. Укытучы безнең киңәшче дә, дус та. Белем бәяләү процессында үзебез дә катнашабыз. Бу – объектив бәяләүнең төп күрсәткече.

**Ильмира Гайнутдинова:**

Ләйсән Фәһәметдиновнаның биология дәресләре бик үзенчәлекле үтә. Үз-үзенә карата да, безгә, укучыларга карата да үтә таләпчән укытучыбыз һәр дәресенә җитди әзерләнә, кызыклы алымнар куллана, фәннең бөтен тирәнлеген аңлатырга тырыша. Олимпиадаларга, имтиханнарга әзерләү буенча да аның үз системасы бар.

**Ләлә Шәйхетдинова:**

Миңа да биология, химия дәресләре ошый. Беренчедән, мин бу фәннәрдән имтихан бирәм, икенчедән, һәр дәрестә үземә кирәкле лайфхак туплыйм.

**Салават Зарипов:**

Мин билге өчен укымыйм. Билге нинди булу бөтенләй әһәмиятле түгел. Иң әһәмиятлесе – нигезле белем алу. Минемчә, югары сыйныфта укучы үзенә кайсы фән кирәкләчәк профессиясенә кирәк булуын инде хәл иткән булырга тиеш. Шул фәнгә ныграк басым ясап, тирәнтен өйрәнү өчен профиль сыйныфларда белем алу мөмкинлеге бар. Физика-математика, химия-биология яки тарих-җәмгыять белеме юнәлешендәге сыйныфларда бүленеп укыйбыз. Җаның теләгәнен сайлап алырга мөмкин.

**Әмир Миңнегалиев:**

Барлык фәннәрдән дә кирәклерәк фән – физкультура, минемчә. Бала вакыттан ук физик тәрбия, спорт белән шөгыльләнү, актив тормыш алып бару – озын гомер итүнең төп шарты. Сәламәтлекләрен югалткач кына “эх” диючеләр шактый, кызганычка каршы. Мин кечкенәдән спортны үз иттем. Җиңел атлетика, баскетбол, футбол, мини-футбол, хоккей – минеке! ГТО буенча да күрсәткечләрем яхшы. Укытучы-тренерларыбыз И.Н.Сәетгалиев, Д.Г.Шәйхетдинов җитәкчелегендә, без спортта зур җиңүләр яулыйбыз. Гимназия командасы составында ике ел рәттән Татарстан Республикасы командалары арасында җиңеп, Бөтенроссия “Президент уеннары” спорт бәйгесендә катнаштым. Команданың бердәм, әзерлекле, тупланган булуы безгә уңыш китерде. Спорт минем тормышымның аерылгысыз бер өлешенә әверелгән инде. Киләчәгемне спорт белән бәйләмәсәм дә, мин аннан аерылмам дип уйлыйм.

**Динә Бәдертдинова:**

Укытучыны хөрмәт итсәң, аның укыткан фәне дә якын була. Үзләрен яраттырып, укыткан фәннәренә мәхәббәт уяткан укытучыларыбыз шактый. Чулпан Алмазовна, Алена Владимировна, Ирина Тимерхановна, Әлфия Ясәвиевна беек Пушкин теленең нечкәлекләренә төшендерсәләр, Римма Гайсовна, Гөлназ Рәисовна, Чулпан Разитовна, Лилиана Расиховна, Гөлшат Ильясовна дәресләрендә Байрон, Киплинг телендә сөйләшәбез. Эльмира Васильевнаның һәр дәресе – әхлак дәресе. Әдәби китап укып ләззәт алырга өйрәтүче укытучыбызга без барыбыз да гашыйк.



**Назгөл Гайфетдинова:**

Математика - фәннәр патшасы, диләр. Безнең гимназиядә математика патшалары – Лира Нурфаязовна, Рәмилә Сабиржановна, Азилә Рамиловна һәм Гөлүсә Әскатовна. Төгәл фән ияләренә хас булганча таләпчәнлек, аерым бер үҗәтлек белән, фанатларча бирелеп эшләүче укытучылар алар. Кагыйдәләр белмәсәң, эш алгоритмын өйрәнмәсәң, математикада бернинди алга китеш тә булмаячак. Без моны бөтен йөрәгебез белән аңлыйбыз, фән нигезләрен тырышып үзләштерәбез. Тарих, география, җәмгыять белеме дәресләре тормыш итү өчен, күзаллавыбызны үстерү өчен бик кирәкле фәннәр. Гомумән, без гимназиябезне, барлык укытучыларыбызны хөрмәт итәбез.

*Реклама хокукында*

**“ШАЯН - ТВ” КАРА – БУЛЫРСЫҢ ИҢ ШӘП БАЛА!**

*“Шаян - ТВ” каналы ТНВда 1 февральдән бирле эшли инде, әмма әлегә кадәр аны тәүлегенә 30 минут кына карарга мөмкин иде. 12 ноябрь көнне исә тәүлек буе үз эшен алып бара торган балалар өчен татар телендә беренче телеканал ачылды!*

*Телеканалның Shayantv.ru дип исемләнгән сайты эшли башлады. Сайтка килеп керү белән үк без татар мохитенә эләгәбез. Татарча көй яңгырый башлый һәм каналның төп герое Шаян үзе кунакларны каршы ала. Бирегә аның белән сөйләшеп алырга да, уеннар уйнарга да мөмкин. Сайтта онлайн режимда “Шаян-ТВ”ны да карап булачак.*

*Каналда 20 дән артык тапшыру күрсәтелә. Алар арасында тәрҗемә ителгәннәре дә бар, каналның иҗат төркеме тарафыннан эшләнгәннәре дә шактый. “Шаян - ТВ”ның көндәлек эше балаларның татарча сөйләм телен камилләштерүгә, мультфильм, тапшырулар аша туган телгә кызыксындыру тудыруга юнәлтелгән. “Шаян-ТВ”ны бергәләп карыйк!*

# ГИМНАЗИЯ ЯШЬЛӘРЕ МӘЙДАНЧЫГЫ

## ТРЕНДТА БУЛ!

***Яңгыр яугач, гөмбәләр бер-бер артлы тишелеп чыга бит әле? Блогерлар да шул гөмбәләр кебек. Интернетка кердеңме, сине шунда ук бьюти-блогер, трэвел-блогер, фуд-блогерлар «камап» ала… Бүген блогер-балалар да шәхси блогларын гөрләтеп алып бара. Биредә мәктәп укучысына хас булган борчулары, укудан тыш шөгыльләнә торган хоббилары, мавыгулары; әти-әни, дуслары хакында постлар укырга мөмкин. Укучылар үзидарәсе әгъзалары белән бергәләп, кайберләренә күзәтү ясарга булдык. Бәлки, сез дә кызыксынып, блогер булып китәрсез!***

**Динар:** Әйе, Интернет челтәре популярлашу белән, йолдызлар саны артып китте: җырчы, актер, модельләр рәтенә блогерлар да өстәлде. Социаль челтәрләрдә аккаунтың, әйтер сүзең, креатив фикерләвең булса – блогерлык дөньясына эз салынган дигән сүз.

**Алина:** *Шәхси блогны популяр итү катлаулыдыр.*

**Илнур:** Блогларның төп валютасы – лайклар, шәрехләр (коммент) һәм язылучылар (подписчики). Бу иң төп казаныш. Чынлыкта исә, бик конкуренцияле юнәлеш бу. Әгәр дә син реклама ясамыйсың, блогыңны үстермисең икән, моннан бик тиз туюлары ихтимал. Чөнки бушлык нәтиҗә бирмәячәк. Мин бүгенге көндә дә унлаган, йөзләгән ташландык блогларны күзәтәм. Кемдер блогын алып бара башлаган, анда әти-әнисе, туганнары, классташлары язылган һәм вәссәлам: блог онытылган. Бу блог түгел, ә гади көндәлек булып калачак.

**Алина:** *Динар, блогны үстерү өчен нәрсә киңәш итәр идең?*

**Динар:** Беренче чиратта, блогерның ачык максаты булырга тиеш, минемчә. Кайда булган, нәрсә ашаган, кайда егылган - болар белән популяр булып булмый. Синең подписчикларың моннан бик тиз туячак. Блогыңны даими рәвештә үз аудиторияң зәвыгына туры килерлек яңалыклар, кызыклы һәм эчкерсез язмалар белән тулыландырып торсаң, син уңышка ирешәчәксең.

**Алина:** *Instagramда нинди яңа трендлар популяр? Яшьләр сленгында "хайп", "хайпта булу" кебек термин популярлашып китте. Шул турыда сөйләшеп алыйк әле.*

**Айгөл:** Соңгы көннәрдә кашларын урта бер җирдән шрам кебек кисеп куюу трендка әверелде.

**Гүзәл:** Бер фразаны алып, шуны видеоролик итеп кую тренд санала.

**Эльгина:** Хайпта булу өчен, яңа трендлар турында хәбәрдар булу кирәк. Бүгенге көндә шактый күп трендлар барлыкка килде. Bathleisure дип аталган тренд турында беләсезме? Әлеге төшенчә инглиз телендәге «ванна бүлмәсе» һәм «спорт киеме» сүзләреннән алынган. Аның мәгънәсе бик гади: башыңа сөлге ураган килеш үзеңне фотога төшерергә кирәк. Бу фотоны ваннада гына түгел, теләсә кайда ясарга мөмкинсең. Bathleisure тренды Рита Орадан башланып киткән. Ул – Британия җырчысы, тумышы белән Албаниядән булган актриса. Нәкъ менә Рита 2017 елның ноябрендә MTV EMA премиясендә халат киеп һәм башына сөлге урап чыккан. Бер ай да үтми, җырчы Рианна «Vogue Paris» журналы тышлыгында бу образда сурәтләнә. Ләкин анда Рианна халат урынына өстенә тун кия.

Instagram кулланучыларына шул гына кирәк тә! Алар хайпны минуты-секундында тотып өлгерә! Рита Ораның җиңел сөлгесен-нән башланып киткән фото трендка әверелгән дә куйган. Хәзер бик күпләр Instagramда #bathleisure дигән хэштег белән фотоларын урнаштыра-лар. Бәлки синдә сөлгеле хайпны тотып алырсың.

**Алина:** Димәк, ваннадан чыккач, шунда ук селфига төшәргә кирәк! Киресенчә булса, хайпта булмыйча калырга мөмкинсең.

*Айрат, үзебезнең гимназия укучылары арасында иң актив блогерлар кемнәр?*

**Айрат:** Instagramда гимназия укучыларының шәхси блоглары шактый. Иң активлары: @m.leysaan 1026 язылучысы булган Ләйсән Мәгъдәнова блогында позитив постлар, фәлсәфи эчтәлекле текстлар бик күп.

**@shams_gu** Гүзәл Шәмсетдинова кәефне күтәрерлек, югары сыйфатлы фотолар белән аерылып тора. Аның 722 подписчигы бар.

**@sun_ray25** Сабитова Айгөл – бию костюмнары белән оригиналь фотолар куя, иң позитив, мәгънәле һәм эчкерсез язылган постлар иясе.

Зарипов Салават **@mad_christ-mas** блогында сәхнә арты серләре ачыла.

Элина Фаттахова **@madam08**




блогында тәмле тортлар пешерә. Матурлыгы белән, оригинальлеге үзенә тартып торган бу тортлар 729 подписчик җыйды. Аны тиздән күренекле фуд-блогерлар рәтендә күрербез дип ышанам.

**Динә:** Мине постларның эчтәлеге кызыксындыра, чын күңелдән, үз сүзләре белән язылган постлар ошый. Зәвыклы фотолар күңелемне җәлеп итә.

Мәсәлән, **@stu_ananasik** - Анастасия Выборнова, трэвел-блогер буларак, табигатьнең иң матур мизгелләрен фотога төшерә һәм редакцияләп урнаштыра. Мин мондый фотоларга битараф кала алмыйм.

**@ivi._kivi** – Ильвина Нуриева эстетик фотографияләр остасы буларак инстаграммчыларга таныш.

**@mirusha03** Ильмира Гайнут-динова кешеләргә мотивация бирерлек постлар, публикацияләр кертеп бара.

**@tatarki4930** Харитонова Рената һәм Шәйхәйдәрова Илзирә үзләренең уртак блогында оригиналь видео һәм клиплар төшереп куялар. Алар яңа гына барлыкка килде һәм тиз популярлык казанды.

Әхмәтҗанов Булат ВК да үзе язган музыкаларны куеп бара. Искиткеч матур, заманча мелодияләр иҗат итә Булат.

Иң күп язылучы - **@_s_alin_r_** Салахова Алинәнең 2692 артык подписчигы бар.

***Мәгълүматларны Алина Ханнанова туплады***

ТЫЛСЫМ+

Декабрь, 2018 нче ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Ханнанова Алина
**Корректорлар:** Сабитова Айгөл
Әхмәтҗанов Булат
**Корреспондентлар:** Бадертдинова Динә
Нассер Мәрьям

**Дизайнер:** Харитонов Динар
**Компьютерда җыючылар:**
Латыпов Таһир
Хафизова Ильгина
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym